2014 ГОД КУЛЬТУРЫ

Мин җыр булып калам әле...

Нефть төбәгенең горурлыгы булган шәхесләр арасында шагыйрә Энҗе Мөэминова аерым урын алып тора. Гомеренең күп елларын балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, шул ук вакытта татар шигъриятендә үз фикере, үз стиле булган әдәби мирас булдыруга ирешкән бу ханымның тормыш сынауларына бирешмәгән көчле ихтыяры соклану уятырлык.

Агымдагы елның 18 маенда Энҗе Мөэминовага 90 яшь тулыр иде. Әлеге истәлекле датаны лаеклы үткәрү өчен район башлыгы урынбасары Нажия Хәйдәрова рәислегендә ветераннар советы, язучылар оешмасы, мәдәният, мәгариф идарәләре вәкилләре составында махсус комиссия эшләде. Чираттагы утырышларның берсендә шагыйрә озак еллар балаларга белем биргән Габдрахман авылы мәктәбе бинасына мемориаль такта кую турында карар кабул ителгән иде. Әлеге чараларны тормышка ашыру Энҗе Мөэминованың укучысы, ТР Дәүләт Советы депутаты Шәфәгать Тәхаветдиновның матди ярдәме белән мөмкин булды.

16 май көнне мемориаль тактаны ачу тантанасы районыбызның мәдәни тормышында зур вакыйга булып тарихка язылды. Чарада Әлмәт муниципаль районы башлыгы Мәҗит Салихов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рәфис Корбанов, ТР Дәүләт Советы депутаты Шәфәгать Тәхаветдиновның ярдәмчесе Рөстәм Гарипов, Габдрахман авылы җирлеге башлыгы Өлфәт Усманов, шагыйрәнең якыннары, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, укытучылар, укучылар катнашты.

- Безнең төбәкләрдә шагыйрә Энҗе Мөэминова кебек шәхесләр тууына һәм иҗат итүенә без чиксез горурланабыз. Әлеге буын кешеләре бернинди авырлыкларга карамастан, сугыштан соңгы авыр елларда халык хуҗалыгын торгызганнар, балаларга белем биргәннәр, шул ук вакытта, әдәбиятебезнең алтын фондына кереп калырлык әсәрләр иҗат иткәннәр. Шагыйрә иҗатындагы фәлсәфи фикер, күңелләргә үтеп керерлек хисселек аны бүген дә укучылар өчен кызыклы итә, - диде район башлыгы үзенең тәбрикләү сүзендә. Социаль һәм мәдәни юнәлештәге барлык башлангычларны тормышка ашыруда ярдәм итүләре өчен "Татнефть" ААҖнә, барлык нефтьчеләргә олы рәхмәтен белдерде.

Энҗе Мөэминова Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Абдулла Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе, укытучы һәм шагыйрә. Аның әдәбияткә килүе дә үзенчәлекле. "Мин әткәйне бик ярата идем. Һәм гомерем буе аны югалтудан куркып яшәдем. Ялгыз калган чакларымда аны үлгән итеп күз алдыма китерә идем дә, әйтәсе сүзләремне шигырь юлларына сала идем. Мине шигърият дөньясына алып кереп киткән "Әткәм чүкеченең тавышы" поэмасының бер сулыштан язылуына шулар да сәбәпче булгандыр", - дип язган соңрак Энҗе Мөэминова.

17 яшеннән мәктәпкә укытучы булып килгән кыз, математик формулалар укытып, дәфтәр тикшереп арыганнан соң, куыклы лампа яктысында төннәр буе шигырь яза. Хәер, шигырь генә язды микән? Билдән кар ерып урман кисү, орлык ташу, укытучы - агитатор өлешенә туры килгән эшләр, тагын никадәр физик һәм рухи яктан авыр гамәлләр булган ул вакытларда.

Ә гаилә, ир, балалар? Хатын назы, ана җылысы? Бу сыйфатлар шагыйрәнең һәрбер шигъри энҗе таҗында балкыйлар. Шагыйрә Энҗе Мөэминова исеме 1961 елдан бирле шигъриятта тулы хокук яулаган исем. 1961 елда "Ефәк яулыгым" дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күргәч, китап һәм шигърият яратучылар Э.Мөэминова исемен аерым бер җылылык белән телгә алалар. Шушы шигырь китабы аңа Татарстан язучылар берлегендә әгъза булу өчен дә мандат кебек була. 1963 елдан ул язучылар сафында.

Һәр әдип - ул кабатланмас шәхес. Иҗат өчен җирлек бар, мәйдан киң, дәртең ташып тора икән - яз да яз. Язганың бары тик әдәбият һәм әдәп кысаларына гына сыйсын. Өлкән шагыйрәбез Энҗе апа да гомере буе язган. Аның өч дистәгә якын китабы дөнья күргән, шигырьләренә җырлар язылган. Язмыш аны тагы бер кат сындырмакчы булып, күзләренең нурын алгач та, ул иҗат итүдән туктамый.

Бу хакта үзләренең чыгышларында ТР Язучылар берлеге рәисе Рәфис Корбанов, авыл җирлеге башлыгы Өлфәт Усманов та әйтеп уздылар. Чыгышлардан соң Габдрахман урта мәктәбе бинасына куелган мемориаль такта янәшәсенә шагыйрә истәлегенә чәчәкләр куелды.

Энҗе Мөэминованың 90 еллыгына багышланган искә алу кичәсе Габдрахман авылы мәдәният йортында дәвам итте. Кичәне рәсми рәвештә район башлыгы урынбасары Нажия Хәйдәрова ачты. Чара шагыйрәнең шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар, театральләштерелгән күренешләр һәм "Татнефть" ААҖ "Хәзинә" газетасы баш мөхәррире Илшат Миңгәрәев, шагыйрәнең улы Расих Мөэминов, каләмдәше, укытучы-шагыйрә Клара Булатованың чыгышлары белән үрелеп барды. Язучылар, Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге рәисе Ильяс Салахов исеменнән Әлмәт язучылар бүлеге җитәкчесе Рәфкать Шаһиев тәбрикләде.

Аларның барысы Энҗе Мөэминова иҗатының киңлеген, кабатланмас булуын ассызыкладылар, истәлекләре белән уртаклаштылар.Шагыйрә бүген дә халык күңелендә җыр булып яши, моң булып яңгырый.

Фәрдия ХӘСӘНОВА
Руслан Бажутов фотолары

очрашулар

17 нче мәктәптә шигърият көне

Балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, ана теленең зурлыгын, кирәклеген аңлату юнәлешендә замана куйган кырыс таләпләргә карамастан, актив эшләүче мәгариф учреждениеләре бар. Шәһәребезнең 17 нче мәктәбе коллективы шундыйларның берсе. Биредә туган телебездә төрледән-төрле чаралар уздырыла. Апрель ахырында "Альметьевский вестник" газетасы мөхәррияте дә әлеге кунакчыл белем бирү учреждениесендә булды.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай туган көне, туган тел бәйрәменә багышланган чараны 17 нче мәктәпнең татар теле укытучылары Римма Таҗиева, Рәмзия Вафина, башлангыч сыйныф укытучысы Кәмәрия Девитаева оештырды.

Туган тел бәйрәмендә мәктәпнең иң актив, иң талантлы укучылары катнашты. Алар олуг шәхеснең тормыш юлы белән таныштылар, сәнгатьле итеп шигырьләрен сөйләделәр. Очрашуда без 17 нче мәктәптә талантлы балаларның күп булуына тагын бер кат инандык. Ринат Хәкимов, Алина Абдулманова, Аделина Нуртдинова, Нияз Кәшипов, Рамазан Рәхимҗанов, Алина Даутова, Сабина Харисова үзләре иҗат иткән шигырьләрен сөйләделәр.

Очрашуда "Альметьевский вестник" газетасы баш мөхәррире Ландыш Зарипова да чыгыш ясады. Ул басманың укучылар өчен иркен иҗат мәйданы булуы, "Алтын каләм-Золотое перо" республика балалар матбугаты фестивалендә катнашу зарурлыгы турында сөйләде. "Сез озак еллар дәвамында газетабызның тугры дуслары булдыгыз. Киләчәктә дә бергә булыйк, газетаны яздырыгыз, укыгыз",- диде ул чыгышын тәмамлап. Очрашу ахырында татар теленең куллану даирәсе, ана телебезне яшьләргә кызыклырак итү проблемаларына багышланган түгәрәк өстәл артында сөйләшү булды.

Редакциябез хезмәткәрләре өчен, чын мәгънәсендә, истәлекле бәйрәмгә әверелгән очрашу уздырганнары өчен 17 нче мәктәп коллективына олы рәхмәтебезне белдерәбез.

Ф.САБАЛЫ

истәлекле көн

Тату гаилә - ил күрке

Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясенең 1993 елның 20 сентябрендәге карары нигезендә, 1994 елдан башлап ел саен 15 май көнендә Халыкара гаилә көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан, 15 май көнне Миңлебай станциясе клубында үзенә бер матур да, истәлекле дә, күркәм гаилә бәйрәме үтте.

Элек-электән гаилә ныклыгын, өлкән буын белән мөнәсәбәтләрне чагылдыручы гаилә бәйрәмнәре гореф-гадәткә кереп китте. Район мәдәният йорты оештырган "Тату гаилә - ил күрке!" дип исемләнгән кичә - очрашу бәйрәме шундыйларның берсе. Гаилә бәйрәменә Даутова Рәйсә Ринат кызы һәм Даутов Илдар Марс улы гаиләсе, Кәримова Ландыш Гали кызы һәм Миннеханов Нәҗип Мөхәммәтхан улы, Шәймөхәммәтова Мәсхүдә Мөхәммәтхан кызы һәм Шәймөхәмметов Марсель Нуриәхмәт улы, Сафиуллина Зәрия Гали кызы һәм Сафиуллин Нәкыйп Хаҗи улы гаиләсе, Ганиева Нурия Гали кызы һәм Ганиев Гамил Шамил улы гаиләләре чакырылган иде. Авыл клубының тамаша залында татар милләтенә генә хас җылылык белән бизәлгән өстәлләр артында барган бу бәйрәм гаиләләр өчен дә, тамашачы өчен дә бик истәлекле булып, онытылмас хәтирәләрне искә төшереп,гөрләп үтте. Гаиләләр арасында 55 ел бергә гомер иткән Сафиуллиннар, 45 ел бергә гомер кичергән Ганиевлар үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

Бу бәйрәмне тирән эчтәлекле матур җырлары белән Таһирә Шәйдуллина, Айнур Сәйфиев, Алсу Мансуровалар, матур биюләре белән Айгөл Минхәеровалар тәбрикләде. Кичәне онытылмаслык итеп, гаиләләрне бер-берсенә тәңгәл итеп Исламия Ханнанова алып барды. "Яшь күңелләр" халык гармунчылар ансамбле кичәнең бизәге булды.

Т.Т.ШӘЙДУЛЛИНА,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, район мәдәният йорты методисты